РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 29 июне** **Чистай шәһәре** **№ 102**

Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарлары нигезендә, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына 96 пунктны өстәп, Кушымта нигезендә, өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Ф.М.Садыйков

Чистай шәһәре
Башкарма комитетының
2022 елның __ июнендәге
__ номерлы карарына
кушымта

Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 97. | Чистай шәһәре, Пушкин ур., 172 А йорт | яшелчә, җиләк-җимеш, кипкән җиләк-җимеш, бахча культуралары | сәүдә палаткасы | 1 | сезонлы |